Республика Татарстан
Совет Петровско-Заводского
сельского поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

22 ноября 2024 ел

№ 14

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында**

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нче елларның планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» гы мәгълүматны тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башкарма комитеты Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нче елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе

Р.Р.Нуртдинов

Кушымта 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенен 2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Хисап | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | кеше | 1432 | 1397 | 1386 | 1374 | 1353 | 1339 |
| Темп роста к предыдущему году | % | | | | | | |
| Эре мөгезле терлекләр саны | Баш саны | 640 | 633 | 653 | 651 | 649 | 647 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Инвестицияләр | мең сум | | | | | | |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Торак төзелеше | кв.м. | 0 | 0 | 60 | 60 | 60 | 60 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Хезмәткә түләү фонды | мең сум | 24743,9 | 30816.2 | 34853.1 | 38303.6 | 41942.4 | 46010.8 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | | | | | | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 41239,8 | 51360.3 | 58088.5 | 63839.36 | 69904.0 | 76684.7 |
| Эшчеләр саны | кеше | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 |
| Эшкуарлар саны (КФХ) | кеше | 30 | 32 | 34 | 37 | 37 | 35 |
| Эшсезләр саны | кеше | - | 1 | 1 | 2 | 2 | 2 |

Петровский Завод авыл җирлеге бухгалтеры Моисеенко В.П.

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенен 2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәк булган төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

2025-2027 нче елларга Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән 2025-2027нче елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенең сценар шартларының база варианты нигезендә эшләнде, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең 2023 елның көтелгән нәтиҗәләрен һәм 2025-2027 елларда икътисад һәм социаль өлкәне үстерү тенденцияләрен, 2025-2027 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып, барлыкка килгән социаль - икътисадый үсеш торышын анализлап чыгару максатында, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә анализ ясалды.

2025-2027 елларда «Urals» нефтькә бәяләр баррель өчен 66,5 АКШ доллары дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана.

2025 елда доллар курсы уртача еллык АКШ доллары өчен 98,6 сум, 2026 елда – 101,2 сум булыр дип фаразлана. 2027 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 103.8 сум тәшкил итәчәк.

Петровский Завод авыл җирлеге Петровский Завод, Димитарлау, Пробуждение, Мостафин, Кук-Тау авылларыннан тора.

2025 елга Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегендә халык саны – 1374 кеше, 2026 елга – 1353, 2027 елга 1339 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Агрокөч төркеме» ЯАҖнең «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖенең, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның потенциалын һәм бүгенге үсеш тенденцияләрен, шулай ук «агросәнәгать комплексын үстерү», «шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү»программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Сарман» агрофирмасы ҖЧҖ «АГРОСИЛА ГРУПП» ЯАҖ,"Валиев М.В.", «Шархемуллин Р.Р.», «Тазетдинов М.М.» КФХлары эш алып бара.